СӨЙ ГОМЕРНЕ, СӨЙ ХАЛЫКНЫ, СӨЙ ХАЛЫКНЫҢ ДӨНЬЯСЫН!

# ДУСЛЫК

НУРЛАТ РАЙОНЫ ИҖТИМАГЫЙ - СӘЯСИ ГАЗЕТАСЫ.
ОБЩЕСТВЕННО-ПОЛИТИЧЕСКАЯ ГАЗЕТА НУРЛАТСКОГО РАЙОНА.

2 декабрь, 1998 ел.
ЧӘРШӘМБЕ

Газета 1931 елның 9 июленнән бирле чыга. | № 137 (8294) | Бәясе билгеләнгәнчә

# ГӘЙТӘНГӘ ДӘ КИЛДЕ ГАЗ

***Үткән җомга Гәйтән авылы өчен тарихи көнгә әйләнде: биредә тәүге тапкыр беренче йортларда табигый газ кабызылды.***





Вакыйга авыл өчен чын мәгънәсендә бәйрәмгә әверелде. Бу аңлашыла да. Гомер буе авыр тормыш - көнкүрешен җиңеләйтим дип хезмәт куйган авыл кешесе өчен бу җиңеллек нәкъ [иллегибле]отка челтәрле газ керүдән башлана бит. Тантанада район хакимияте башлыгы Ф.С. Сибагатуллин шул фикерне ассызыклап: "Гәйтән бүген яңа дәвергә аяк басты,- диде. - Газ сезне ягулык хәстәрен кайгырту, мичкә ягу кебек борчу - мәшәкатьләрдән арындырачак. Димәк, тормыш никадәр авырая дисәк тә, газлы булгач, алга, яхшыга барачакбыз".

Дөрес, гәйтәнлеләр бу көнне аз көтмәделәр: авылны газлаштыру эшләре 5 ел элек башланган иде, һәм бу еллар акча бәясенең көннән-көн төшүе, газ кертү өчен кирәк - яракларга бәяләрнең әкияттәгечә күтәрелү чорына туры килде. Авыр булуга карамастан, халык өйләрен газ кертүгә әзерләргә тырышкан, ә район җитәкчеләре тарафыннан Гәйтәнгә газ линиясен сузу турында Димитровград шәһәренең 14нче МСУ участогы белән килешү төзелгән. Һәм бу эшне тулысынча В.С.Кузнецов җитәкчелегендәге 14нче участок башкарып чыккан.

Челтәрле газ линиясенә иң беренче чиратта Алексей һәм Елена Пайгерчевлар йорты тоташтырылды. Алар хуҗалыкта тырыш һәм алдынгы хезмәтчәннәр, өч бала тәрбиялиләр.

- Бу зәңгәр ут гаиләгезгә бәхет, тынычлык, иминлек алып килсен,- дип Ф.С.Сибагатуллин газ плитәләрен кабызып җибәрде. Кунаклар, авыл халкы белән тулы өй эче алкышларга күмелде. - Инде булганның кадерен белеп, саклык чараларын истән чыгармыйча, хәвеф - хәтәрсез файдаланасы гына кала,- дип өстәде хаким.

- Көтеп алынган шатлыклы көнебез,- диделәр йорт хуҗалары - кунакларны зәңгәр утта пешкән коймаклар белән сыйлап. - Бәхет бит. Күңел дә ышанмый хәтта.

Нәкъ шуңадыр инде, Алексей утынны быел да мулдан әзерләгән. Өйдә аның 78 яшьлек әнисе Анна Яхвоновна да яши. Тату гаиләләренә җиңеллек китерүчеләргә ул да олы рәхмәтләрен укый.

Ул көнне аларның күршеләре - кызы һәм кияве Волковлар гаиләсе белән бергә Елизавета Гавриловна Клементьеваларга да тоташтырылды газ. 91 яшьлек карчык та бу көнне күрүенә бик шат. "Мин инде яшисен яшәгән, яшьләр, киләчәк буын өчен куанам",- ди ул.

Гәйтән әлләни зур авыл түгел: 200ләп йортта 500ләп кеше яши. Әмма алга таба үсүе бик ихтимал, яшьләрнең күбесе авылда кала хәзер, киң, якты мәктәп тә шаулап тора.

- Газ беренче йортларга кергәч, рәхәтләкне күреп бөтен авыл кузгалачак, тизрәк кертергә тырышачаклар - эш чылбыр реакциясе сыман барачак, - ди район авыл хуҗалыгы һәм азык - төлек идарәсенең капиталь төзелеш бүлеге начальнигы М.Х.Миннебаев. - Документация әзер. Авылны тулысынча газлы итәр өчен хәзер бар эш КХА җитәкчесе һәм һәр йорт хуҗасының үзеннән генә тора.

**Ф.ЗЫЯТДИНОВА.**

**Рәсемнәрдә: газ кабызу тантанасыннан күренешләр. Сулда А.Я.Пайгерчева.**

**Н.АЗИЗОВ фотолары.**

# ҮРНӘК ИТӘРГӘ ДӘ, ГЫЙБРӘТ АЛЫРГА ДА ҖИРЛЕК БАР

## *Семинар - киңәшмә үтте*

***Дүшәмбе көнне хуҗалык рәисләре, агропромышленность комплексының эшкәртү һәм хезмәт күрсәтү предприятиеләре һәм оешмалары җитәкчеләре, хакимиятнең бүлек башлыклары, авыл хуҗалыгы һәм азык - төлек идарәсенең баш белгечләре катнашында узган семинар - киңәшмәдә сүз беренче чиратта терлекчелектә унбер айлык эш нәтиҗәләренә йомгак ясау, быелгы катлаулы шартларда бу тармакта тотрыклылыкны саклап калу юллары турында барды. Анда катнашучылар районның "Өмет" агрофирмасының барлык кооперативлары терлекчелек объектларында да булып, хезмәтне оештыру, малларны карау һәм ашату технологиясе таләпләренең ничек үтәлеше белән якыннан таныштылар.***

***Семинар - киңәшмәне хакимият башлыгы Ф.С.СИБАГАТУЛЛИН алып барды.***

Бу хакта тәфсилле язманы газетабызның алдагы саннарында укырсыз.

## *Рәсми*

# ТАТАРСТАННАН ЧИТКӘ ЧЫГАРУ ТЫЕЛГАН АЗЫК - ТӨЛЕК ТОВАРЛАРЫН САТУ, АЛГА ТАБА ЮККА ЧЫГАРУ ҺӘМ ФАЙДАЛАНУ ТӘРТИБЕ ТУРЫНДА

***Халыкны азык - төлек белән тәэмин итүдә өзеклекләргә юл куймау максатында ТР Министрлар Кабинеты быелның 19 ноябрь күрсәтмәсе белән, Татарстаннан читкә чыгару тыелган һәм тоткарланган азык - төлек товарларын сату тәртибе турында 843 номерлы Вакытлы инструкцияне раслады.***

Вакытлы инструкциядә азык - төлек товарларын тоткарлау хокукы ТР Эчке эшләр Министрлыгының, санэпидкүзәтү дәүләт комитетының, ТР Министрлар Кабинетының баш ветеринария идарәсенең моңа вәкаләте булган урындагы затларына бирелүе каралган.

Татарстаннан читкә чыгару рөхсәт ителмәгән азык - төлек товарлары исемлегендә:

*ит продуктлары,*
*сөт продуктлары,*
*маргарин,*
*үсемлек мае,*
*он,*
*ярма,*
*макарон әйберләре,*
*шикәр,*
*чәй,*
*балалар ризыгы,*
*тоз,*
*балык һәм балык продукциясе,*
*суелмаган йорт хайваннары һәм кошлары* бар.

**(Ахыры 4нче биттә).**

## *Тиздән - Шәһәр көне*

# КАЙСЫ УРАМ, КАЙСЫ ЙОРТ ЯМЬЛЕРӘК?

11 - 12 декабрьләрдә Нурлатта Шәһәр көне һәм кышкы трюк автоузышлары үткәрелү уңаеннан шәһәрдәге административ биналарны, производство участокларын, урамнарны, мәйданнарны, йортларны Яңа елга матуррак итеп бизәү буенча конкурс игълан ителде. Биналарның фасадларын һәм әйләнә - тирәләрен бизәгәндә Яңа ел кунагы - яшел чыршыны да, төсле гирляндалар, яктыртулы таблолар, кар сыннар һәм күп кенә башка декоратив элементлар да кулланырга мөмкин.

Конкурска йомгакны оештыру комитеты ясаячак.

# ЗИРАТ ТИРӘСЕ ТОТЫЛА

Нурлат районы мөхтәсибәте яңа зират тирәсен тотуда ярдәм итүләрен сорап мөселманнарга бер тапкыр мөрәҗәгать белән чыккан иде инде. Хәзер РСУ зират тирәсен 100 метрлап коймалады да, эш дәвам итә. Әмма халыктан да бераз ярдәм булса, бу эш тагын да җанланып китәр иде, дип Нурлат районы мөхтәсибе Зәкиулла хәзрәт Әхмәтшин тагын бер тапкыр нурлатлыларга, оешма, предприятие җитәкчеләренә мөрәҗәгать итә. Мәңгелек йортыбыз турында кайгырту һәркемгә савап кына китерер иде, ди ул.

***БЕЛМИ КАЛМАГЫЗ, КИЛМИ КАЛМАГЫЗ!***

# НУРЛАТ СӘХНӘСЕНДӘ - РАМИЛ МИФТАХОВ



***Район мәдәният йортында якташыбыз - композитор һәм башкаручы Рамил Мифтахов үзенең концерт бригадасы белән "Җырламыйча ничек түзим" дигән зур концерт программасы тәкъдим итә.***

**Концерт 10 декабрьдә 19.00 сәгатьтә була.**

**Билет бәясе - 10 сум.**

***Инвалидлар унксөнлегендә үтүен исәпкә алып, Рамил концерттан җыелган акчаның бер өлешен районның инвалидларга ярдәм фондына күчерергә ниятли.***

## *Белеп торыгыз*

# КАЗАНГА - АЕРЫМ ВАГОН

Нурлат белән Казан арасында тагылма тимер юл вагоны йөртелә башлады. 54 урынлы плацкарт вагон Нурлаттан так көннәрдә 909нчы Чиләбе - Мәскәү поездына тагып 14 сәгать 40 минутта озатыла. Вагон Казанга икенче көнне иртән 4 сәгать 15 минутта килеп җитә.

Казаннан ул вагон җөп көннәрдә төнге сәгать 10да 919нчы Казан - Волгоград поездына тагып озатыла һәм Нурлатка икенче көнне көндезгә 12дә килеп җитә.

Билет хакы - 67 сум.

# «ДУСЛЫК»КА ЯЗЫЛУ БАРА

***1999 елның беренче яртысы өчен "Дуслык" ("Дружба", "Туслах") район газетасына язылу бәясе - 25 сум 20 тиен. Бөек Ватан сугышында катнашучыларга һәм инвалидларга, Әфган сугышында булучыларга, Чернобыль атом электр станциясендәге фаҗига нәтиҗәләрен бетерүдә катнашучыларга тиешле документлар нигезендә 50 процент ташлама ясала.***

## *ДЕКАБРЬДӘ МАГНИТЛЫ КӨННӘР*

2, чәршәмбе (14 - 16 сәгатьләр),
4, җомга (15 - 17 ),
9, чәршәмбе (11- 13),
11, җомга (11 - 13),
19, шимбә (7 - 9),
24, пәнҗешәмбе (10 - 12),
26, шимбә (11- 13),
29, сишәмбе ( 12 - 14).

# КАРТЛАР СҮЗЕН КАПЧЫККА САЛ

***Инде хәбәр иткәнебезчә ("Дуслык",№ 128), Октябрь инкыйлабы көнендә Яшьләр үзәгендә булып үткән очрашуда катнашкан сугыш һәм хезмәт ветераннарын хакимият башлыгы Ф.С.Сибагатуллин районддагы алдынгы тәҗрибә маршрутлары буйлап йөртеп кайтырга ышандырган иде.***









***Рәсемнәрдә: Ветераннар Советының элеккеге һәм яңа рәисләре; очрашу әнә шулай күңелле үтте.***

Хаким әйткән сүзендә торды - узган шимбә көн өлкәннәрне шул ук составта хакимият бинасына чакырдылар. Дөрес, бу юлы җыелышуның тагын бер сәбәбе бар иде. Башта сугыш һәм хезмәт ветераннары район Советының чираттагы пленумы булды. Анда катнашучылар узган пленумнан соң арабыздан киткән Совет әгъзаларын минутлык тынлык белән искә алдылар. Пленумда нигездә оештыру мәсьәләләре каралды. Пленум, И.У. Гыйләҗевны шәхси гаризасы нигезендә һәм сәламәтлеге буенча Совет рәисе вазифаларыннан азат итте. Хакимият башлыгы Ф.С. Сибагатуллин аңа бу постта озак вакыт намус белән һәм нәтиҗәле эшләгәне өчен рәхмәт белдереп, Ветераннар оешмасының югары бүләген - күкрәк билгесен, шулай ук чәчәк бәйләме һәм истәлекле бүләк тапшырды. Ислам Усманович үзенең җавап сүзендә аңа күрсәтелгән олы хөрмәт өчен рәхмәт әйтеп, оешма эшчәнлегендә киләчәктә дә хәленнән килгәнчә актив катнашачагын, үзенең бай тәҗрибәсен кызганмыйча бүлешәчәген әйтте.

Пленум Совет президиумы члены һәм район сугыш һәм хезмәт ветераннары Советы рәисе итеп бертавыштан Замир Шамил улы Билдановны сайлады. Совет членнары, аерым алганда, пленумда чыгыш ясаган С.С.Идиятуллин һәм башкалар, гади колхозчыдан башлап зур җитәкче дәрәҗәсенә кадәр күтәрелгән, озак еллар райондагы иң алдынгы хуҗалыкларның берсе булган "Татарстан" колхозын җитәкләгән, фидакарь хезмәте өчен хөкүмәтебезнең күп кенә бүләкләре, шул исәптән Ленин ордены белән бүләкләнгән, пенсиягә чыкканнан соң да хезмәтен дәвам иткән Замир Шамиловичның бу җаваплы постта да зур энергия белән эшләячәгенә ныклы ышаныч белдерделәр, аңа уңышлар теләп, эшлекле тәкъдимнәр әйттеләр.

Аннары районның алтын фонды булган ветераннарны районның авыл хуҗалыгында бара торган реформалаштыруның иң алдынгы адреслары буйлап сәяхәткә алып чыгып киттеләр. Сәфәрнең максаты икеъяклы иде: бердән, күбесе авыл хуҗалыгы һәм аңа тыгыз бәйле тармакларда, шактые җитәкче постларда эшләгән, үз куллары белән районның халык хуҗалыгын аякка бастырган, бар гомерләрен районның муллыгы хакына хезмәткә багышлаган ветераннарга районыбызның бүгенгесе нинди булуын үз күзләре белән күрергә мөмкинлек тудыру, икенчедән, хуҗалыкларда эшнең ничек оештырылуы, үзгәртеп коруларның барышына карата аларның гадел фикерләрен һәм акыллы киңәшләрен ишетү иде. Картлар сүзен капчыкка сал, дип бер дә белмичә генә әйтмәгәннәр бит борынгылар. Ә ул көнне сәфәр чыккан ветераннар арасында сүз - киңәшләрен чыннан да капчыкка гына салып, кирәге чыккан саен киңәшкә тотардай аксакаллар байтак иде.Берничә колхоз рәисенең әйткән сүзләрен кайбер бүгенге җитәкчеләр капчыкка салудан бигрәк колакларына киртләп куйсыннар дип аерым басым ясап әйтеп үтмичә дә булмас.

Мөхтәрәм ветераннар "Нурлат" агрофирмасының Синдряков исемендәге хуҗалыгында һәм дуңгыз симертү буенча хуҗалыкара берләшмәсендә шушы мөһим тармакта эшнең торышы белән гаять кызыксынып таныштылар. Синдряков исемендәге хуҗалыкның баш бухгалтеры, вакытлыча рәис вазифаларын да башкаручы Н.И.Храмова терлекчелектә хуҗалыкны озак еллар җитәкләгән Николай Леонтьевич Филиппов (авыр туфрагы җиңел булсын) максат иткән үрләргә чыгулары, хәтта аннан югарырак күрсәткечләргә дә ирешүләре турында горурланып сөйләде. Шул чорларда авыл хуҗалыгы һәм азык - төлек идарәсе башлыгы һәм совхоз директоры булган, хәзер инде лаеклы ялда булса да әле агрофирманың генераль директоры урынбасары булып эшләүче Харис Нуруллович Атауллинның агрофирмада дуңгызчылыкны интенсив төстә һәм колачлы алып бару турында хикәяте дә кунакларда зур кызыксыну уятты. Дуңгыз симертү буенча автомат комплекста кунакларның күбесенең үз гомерләрендә беренче тапкыр булулары, элегрәк, үзләре хуҗалык рәисе чакларда килергә туры килгәннәренә дә монда зур кызыксыну һәм соклану белән карарлык яңалык байтак иде. Дөрес, комплексны маллар белән проект куәтендәгечә яки сиксәненче еллардагы кадәрге дәрәҗәдә тутыру өчен эшлисе эш бар әле, әмма элеккеге колхоз рәисләре район җитәкчелегенең бу юнәлештә дөрес курс тотуын билгеләп, аның уңышка илтәсенә чын - чынлап ышануларын әйттеләр. "Киекле" хуҗалыгында малларны бәйләүсез асрау, сыерларны "Альфа - Лаваль" швед фирмасы аппаратлары ярдәмендә саву, сөтне стерильләштереп махсус капларга тутырып чыгару технологияләре белән гаять кызыксынып танышканнан соң, "Өмет" агрофирмасының Кече һәм Урта Камышлы кооперативларына килеп чыккач, авыл хуҗалыгы аксакаллары районда дуңгызчылыкның тамырына балта чабылмаганлыгына, киресенчә, аның яңа бер көч белән аякка басып килүенә тагын бер тапкыр инандылар. Кече Камышлыдагы дуңгыз караучы, теге очрашуда бер өстәл артында утырган апайлар белән күптәнге танышлар кебек күрештеләр кунаклар. Кече Камышлыда инде икенче ел эшләүче, Урта Камышлыда бүген - иртәгә худка җибәрелергә тиешле саву залларына исләре китте аларның. Бозаулар абзарында ветераннардан берсенең:

- Карагыз әле, аллары тулы төрледән - төрле азык, витаминнар, тик ник берсе бер килеп борын төртсен, димәк, тамаклары тук боларның,- дигән сүзләре колакка керде. Ул җәһәттән бер генә фермада да тәртипнең кунакларга күрсәтү өчен генә булмавына һәркем ихластан ышанырлык иде. Ветераннар автомат комплекста һәм ахырдан "Өмет"тә оештырылган мул аш - су табыннары артында утырганда да берсен - берсе бүлә - бүлә әйттеләр бу хакта. Район җитәкчелегенең авыл хуҗалыгын, башка тармакларны да тотрыклы алып бару буенча дөрес юлда булуын ассызыклау белән бергә, ветераннар бу юнәлештә әле тагын да нәтиҗәлерәк эшләргә мөмкинлекләр булуын искәртергә дә онытмадылар. Заманында иң зур хуҗалыкларның берсе белән җитәкчелек иткән С.С.Гафуровның зур ачыну белән әйткән сүзләренә ничек колак салмыйсың ди инде. Кайчандыр өч мең ярым баш дуңгыз асраган һәм барлык керемнең яртысыннан артыгын шул тармактан алып килгән, инде өчкә бүленгән "Игенче" хуҗалыгында бүген бер генә баш та дуңгыз булмавына, аның икенче бер бригадасы булган "Таң"да да дуңгызлар санаулы гына булуына, сарыкларның шулай ук бетеп баруына ничек йөрәге әрнемәсен ди ветеранның. Бу уңайдан Ф.С.Сибагатуллинның эш барсын өчен авылда гына түгел, башка участокларда да беренче чиратта чын, ныклы, шул эшне, шул кешеләрне якын күрә торган хуҗа кирәклеге турындагы фикере белән өлкәннәр барысы да килеште. Әнә бит, кайчандыр ике авыллы "Ленинский путь" хуҗалыгына рәислек итүдән (хезмәт юлын шулай ук шофер булып) башлаган Ильяс Нургалиевич Мөхәммәтов бүген элеккеге дүрт хуҗалыкның ун авылын эченә алган "Өмет" агрофирмасына җитәкчелек итә, һәм эшләре күзгә күренеп алга бара. Сәлим Салихович, бер - ике елда районның башка хуҗалыкларында да шундый тәртип кертеләсенә өметләнүен әйтеп, өлкәннәрнең бу эштә хакимият башлыгына кулларыннан килгән бар ярдәмне күрсәтергә әзер булуларына ышандырды. Үз сүзләре белән әйтсәк, ветераннар әле аларны өч түгел, биш тәрәнле сабанга җиксәләр дә риза, уртак файдага гына булсын. Берочтан, ветераннарның, уенын - чынын бергә кушып, хакимият башлыгының бу постта пенсиягә киткәнчегә кадәр эшләп, район ветераннар Советы рәисе дилбегәсен дә аның кулына тапшырырга насыйп булуын теләүләрен дә әйтеп үтәргә кирәк. Анысы Ф.С.Сибагатуллинның әле бүген - иртәгә генә районнан китәргә җыенмавы турында әйткән сүзләрен куәтләү буларак килеп чыкты.

Ветераннарның район башлыгына кулларыннан килгән бар ярдәмне күрсәтергә әзер булуларына килгәндә, болай да үз гомерләрендә күпне күргән, бар көчләрен, саулыкларын шушы эшкә биргән аксакалларны атлаган саен кузгатып торырга димәгән анысы. Әмма, АТПдан Гариф ага Хәмматвәлиев әйткәнчә, ветераннарның җәмгать тормышында элеккеге еллардагыча актив катнашуы, дөресрәге, аларны катнаштыру, аларны хезмәт коллективларына чакыргалап, киңәш - тәкъдимнәрен, фикерләрен сорашып тору бик кирәк, җәмгатьчелек йогынтысының беркайчан да артык булганы юк. Шул исәптән, гомер иткән картлар сүзен капчыкка салу да мәслихәт.

Очрашуда хакимиятнең халыкны социаль яклау идарәсе башлыгы Л.Н.Дилмөхәммәтова, аппарат җитәкчесе Ф.Р.Ногъманова һәм җәмгатьчелек белән элемтәләр буенча баш белгеч Р. З. Сингатуллина катнаштылар.

**Р.ГЫЙЛЬМЕТДИНОВ.**
**Н.АЗИЗОВ фотолары.**

# «АЛСУ» ИСЕМЛЕ БАКЧА БАР...

"Алсу"-Нурлатта бердәнбер татар телле балалар бакчасы. Быел ул 5нче елын эшли. Беренче ул - юл яручы, яңалык кертүче, шул сәбәпле, тормыш җилләренең иң кырысы да аңа эләгә. Үз юнәлешендә "Алсу"га да нәкъ шул беренчелекне күтәрү вазифасы йөкләнә һәм ничек кенә авыр булмасын, ул балаларны ана телләрендә тәрбияләүне гамәлгә ашырырга тырыша.

Бакчага 130 - 150ләп бала йөри. Татар бакчасы булса да биредә тәрбияләнүчеләр - Нурлатта яшәүче төп өч милләт вәкилләре һәм аларның күбесе өйләренә татар теленең яңгырашын бакчадан алып кайталар. (Өстәмә тел белүнең әле беркемгә дә зыяны тигәне юк). Читкәрәк китеп шунысын да әйтик: бакча хезмәткәрләренә татар гаиләсендә үсүче балалар белән эшләве нәтиҗәлерәк тә, мәшәкатьсезрәк тә, билгеле. Тик соңгы елларда туган телгә уңай караш, яңа мөмкинлекләр ачылуга карамастан, кызганычка каршы,ата - аналар балаларын татар бакчасына бирергә атлыгып тормыйлар. Һәм бу "Алсу" өчен генә түгел, шәһәрдәге башка балалар бакчаларының татар группалары өчен дә катлаулы һәм четрекле проблема булып кала бирә.

Яңа җыелган коллективка - тәрбиячеләр биредә 12әү: бишесе югары белемле, 2се - югары уку йортларында белем ала, калганнары махсус урта белемле - балаларны тәрбияләүдә яңадан - яңа алымнар кертүдә тәүге буразналарны сызарга туры килә. Гомумән, эшкә һәркем хәленнән килгәнчә үз көчен кертә. Эш вакыты турында бәхәсләшүләр юк биредә, "безгә моның өчен түләмиләр" дә димиләр. Кирәк икән - кирәк. Методик кабинетның, бүлмәләрнең буш тартмаларын тутыру өчен һәр тәрбияче эшкә җигелә: төрле тематика буенча альбомнар ясыйлар, методик әсбапларны русчадан татар теленә тәрҗемә итәләр, татарча сценарийлар төзиләр. Берәмтекләп шәһәр һәм аның кешеләре турында, милли киемнәр, фольклор, хайваннар һәм кошлар турында балаларга кирәкле мәгълүматлар җыялар. Рәсем сәнгате студиясе эшли - аны үз эше өчен җан атып торучы Алия Меркулова алып бара. Аның тырышлыгы, иҗади эшчәнлеге нәтиҗәсендә кыска вакыт эчендә кабинет бай күрсәтмә материал белән тулыландырыла.

Бакчаны күркәм хәлгә китерү, тиешенчә бизәү эшләрен дә ул башкара. Аның белән бергә тәрбияче ярдәмчесе Вера Урлаткина да балаларны эстетик зәвык белән тәрбияләүгә зур өлешен кертә - бакчада аның балчыктан ясаган аккошлары, скульптуралары, татар әкиятләре персонажлары тәрбия моментында зур роль башкарсалар, бакчаны бизәү буенча да оригиналь, үзенчәлекле хезмәт үтиләр.

Бакчада татар биюе, оста куллар түгәрәкләре эшли, инглиз теленә өйрәтү буенча беренче адымнарны ясыйлар.

Санаулы гына еллар эшләсәләр дә, тәрбиячеләр бер чараны да читтә калдырмаска тырышалар: ата - аналар белән бергәләп "Әти - әни һәм мин - спорт яратучы гаиләбез", ГАИ ярдәмендә "Юлда йөри беләбезме?", "Нәүрүз", "Сабан туе", "Карга боткасы" кебек күптөрле милли уеннар үткәрәләр. Чаралар видеотасмага төшерелә, фотосурәтләр ясала һәм болар инде бакчаның тарихына салынып кына калмыйча, гаиләләргә дә күчә. Быел бакча үзен видеоаппаратура белән тәэмин иткән, "Малыш" спорт корылмасы алган. Яшелчә, җиләк - җимеш бакчалары туклануда саллы гына файда китергән.





- Идеяләр бик күп, әллә ниләр үткәрәсе килә, коллектив та иҗади инициативалы эшли. Ләкин финанс проблемасы күп нәрсәгә аяк чалып тора,- ди бакча мөдире Фәридә Харисовна Әбҗаббарова. - Нәкъ шул сәбәпле бакчада уенчыклар җитешми, урындык, өстәл кебек җиһазлар да дефицит әлегә.

Фәридә Харисовна - шәһәрдә балалар бакчалары татар тәрбиячеләренең методик берләшмәсе җитәкчесе. Берләшмәнең "Алсу"га җыелуы табигый да. Күптән түгел безгә аның эшендә катнашырга туры килде. Тәрбияче Рамилә Сабирова "Серле чәчәк" методикасына нигезләнеп, урта төркем балалары белән эмоциональ - психологик дәрес күрсәтте. Балаларда уңай һәм тискәре геройларны аеру, уңай һәм тискәре эмоцияләрне ачыклау, күрү, ишетү сәләтләрен, логик фикерләүне үстерү, әхлакый тәрбия бирү һәм башка максатлар куелган иде дәрестә. Тормыш тонусын күтәрү максатында тренинг кебек психологик күнегүләр, күзаллауны киңәйтүгә каралган мавыктыргыч уеннар - балалар боларның һәркайсында үзләрен иркен тоталар, һәр уенга теләп тартылалар. Шунда аларның да, тәрбияченең дә артистлык сәләтләре яхшы ачылды. Гомумән, тәрбияче ул - артист булырга тиеш дигән фикер белән килешмичә мөмкин түгел. Әлеге дәрестән соң күрсәтелгән "Аулак өй"дә шул сыйфатлары ачылды аларның. Бу чарада тәрбиячеләр Гөлсинә Миннеханова, Фәридә Мөхәммәтова, музыка җитәкчесе Гөлсинә Айсина һәм башкалар аеруча оста катнаштылар.

"Алсу" балалар бакчасында проблемалар ничек кенә күп булмасын, алар күтәренке рух, иҗади кәеф белән эшлиләр, балаларны татар мохитендә тәрбияләү, татар милләтенең йола, гореф - гадәтләренә, рухи хәзинәләренә якынайту, тәүфыйклы, итәгатьле, инсафлы итеп үстерү өчен бөтен тырышлыкларын куялар. Иң мөһиме, татар теленең киләчәгенә ышаналар, шуңа да киләчәктә баласын "Алсу"га тәрбиягә бирүче ата - аналар тагын да артыр дип өметләнәләр.

**Ф.ЗЫЯТДИНОВА.**







*Рәсемнәрдә:Әби ролендә тәрбияче Фәридә Мөхәммәтова; «Аулак өй» күренешләрендә өлкән төркем балалары.*

*Н.АЗИЗОВ фотолары.*

# «ДУСЛЫК» - ҮЗЕБЕЗНЕКЕ

Мин "Дуслык" газетасына 1969нчы елдан бирле язылам. Шул еллардан бирле гомерем газета тарихы белән үрелеп бара дисәм дә артык булмас, мөгаен, чөнки шул вакыттан бирле мин андагы һәр мәкаләне генә түгел, һәр сүзне, һәр хәрефне укып барам. Ә аннары үземнең иптәшләрем - сыер савучылар турында, алга таба авылда тырышып эшләүче кешеләр турында үзем дә яза башладым. Башка авыллардан даими язып торучыларны яратып укыйм, булдыра алган кадәр кайберләре белән элемтә дә тотам. Безнең дуслыкны бер нәрсә берләштерә һәм якынайта - ул "Дуслык" гезатасы.

Быел да бик шатланып язылдым мин аңа - ни дисәң дә, 1999нчы елда мин үзенчәлекле юбилей - "Дуслык" белән бәйләнешемнең 30 еллыгына аяк басам.

Иптәшләремне дә газетага язылырга өндим: "Дуслык" бит ул - үзебезнең газета. Ә анда эшләүчеләргә, минем кебек хәбәрчеләргә




киләчәктә дә иҗади уңышлар телим.

**С.ФӘТХЕТДИНОВА.**
**Яңа Әмзә авылы.**

*Кайтаваз*

## КЕЧЕ КҮҢЕЛЛЕ, ДИМӘК, ОЛЫ ҖАНЛЫ

Газетабызның 11 ноябрь санында хакимият башлыгының Яшьләр йортында үткәрелгән район аксакаллары белән очрашуы турында язманы кем генә дулкынланмыйча укыды икән? Бездә, олыларда ул өлкән буын өчен ифрат шатлык хисе, алдагы көнгә өмет, яшәү теләге уятты. Әйе, бу буын олылауга лаек. Сугыштан соңгы елларның авырлыгын күтәрү, күмәк хуҗалыкның иң гөрләп торган чорында җитәкчелек дилбегәсен тоту алар җилкәсенә төшкән бит. Алар, юлсызлык кыенлыгын да, юксызлык читенлеген дә, кул хезмәте авырлыгын да кичереп, халыкны фидакарь хезмәткә туплый белделәр, халык мәнфәгате белән яшәделәр. Шуңа, таләпчән булсалар да, гадел һәм намуслы булулары сәбәпле, авыл кешеләренең ихтирамын казандылар. Һәр проблеманы халык белән уртага салып хәл итteләр, кирәк чакта үзләре дә киңәш - табышка килергә читенсенмәделәр. Мөгаен, аларның 30ар ел җитәкчелек итә алуларының төп сере дә халык белән аңлашып, аралашып эшләүдә булгандыр.

Бу җәһәттән хәзерге буын хуҗалык җитәкчеләренә дә киңәшем бар: җитәкченең төп тәрәге - кешеләр. Үз халкыгыз белән уртак тел табудан, якынаюдан курыкмагыз. Һәр авылның үз аксакаллары, өлкәннәре бар бит. Кайчак алар белән күрешеп сөйләшү, киңәшләшү сезгә дә зыян итмәс иде. Кирәк икән, өлкәннәр гомуммәнфәгатьләр хакына эшкә дә, ярдәмгә дә теләп алыначаклар. Әмма, кызганычка каршы, бездә андый нәрсә күзәтелми әле. Менә безнең "Үрнәк" КХАсында ничәмә - ничә рәис алышынды, ник берсе өлкәннәрне җыеп сөйләшергә омтылып карасын! Ә аннан кем югалта икән - безме, әллә алар үзләреме...

Җитәкче кече күңелле булганда, аның абруе гына үсә, ләбаса!

**И.ШӘЙХИЕВ.**
**Зирекле авылы.**

# ТАТАРСТАННАН ЧИТКӘ ЧЫГАРУ ТЫЕЛГАН АЗЫК - ТӨЛЕК ТОВАРЛАРЫН САТУ, АЛГА ТАБА ЮККА ЧЫГАРУ ҺӘМ ФАЙДАЛАНУ ТӘРТИБЕ ТУРЫНДА

(Ахыры. Башы 1 нче биттә).

Азык - төлек товарларын тоткарлаганда беркетмә төзелә.

Беркетмәдә: аны төзү вакыты һәм урыны, төзегән кешенең вазифасы, фамилиясе, исеме, атасының исеме, кагыйдә бозучы турындагы мәгълүматлар, аның адресы, исәп - хисап счеты, тоткарланган продукция турында мәгълүматлар (исеме, күләме, авырлыгы, продукция берәмлегенең бәясе, продукциянең тулай бәясе) күрсәтелергә тиеш.

Беркетмәгә аны төзегән һәм азык - төлек товарларын алып чыккан затлар кул куя. Аларның икенчесе беркетмәнең эчтәлегенә карата аңлатмалар һәм замечаниеләрен, шулай ук беркетмәгә кул куюдан баш тартуын аңлатып язып бирергә хаклы һәм ул язулар беркетмәгә теркәп куела.

Тоткарланган продукция, аның каян алынганлыгын ачыклаганчыга, сыйфатын һәм куркынычсызлыгын раслаучы документлар алганчыга, шулай ук тиешле экспертиза үткәргәнчегә кадәр, шәһәр, район хакимияте тарафыннан билгеләнгән аерым складка җаваплы кеше кулына сакларга тапшырыла. Продукциянең тереннән һәм экспертиза тереннән чыгып, дәүләт контроле органы (дәүләт ветеринария күзәтүе, дәүләт сәүдә инспекциясе, дәүләт санэпидкүзәтү һ.б.) вәкиле тарафыннан лаборатор тикшертүгә җибәрү өчен уртача проба алына.

Азык - төлек товарлары сыйфат таләпләренә туры килмәгән очракта ул товарлар, чыгарылган нәтиҗә нигезендә, промышленностьта кабат эшкәртелергә яки юкка чыгарылырга тиеш.

Сыйфатлы продукция шәһәр, район хакимиятләре тарафыннан билгеләнгән ваклап сату сәүдә предприятиеләре аркылы сатыла.

Тоткарланган продукцияне промышленность эшкәртүенә яки сатуга тапшыру һәм кабул итеп алу мөлкәтне теркәү акты буенча башкарыла. Актта продукциянең күләме һәм бәясе, аның иясенә түләнергә тиешле акча суммасы күрсәтелә. Промышленность эшкәртүенә яки сатуга тапшырыла торган продукция өчен күчерелергә тиешле акча күләме эшкәртүгә һәм сатуга киткән чыгымнарны искә алып һәм билгеләнгән тәртиптә ачыклана.

Продукцияне промышленность эшкәртүенә яки юкка чыгаруга тапшыру дәүләт санэпидкүзәтү яки дәүләт ветеринария күзәтүе органнары карары буенча башкарыла.

Промышленность эшкәртүенә яки сатуга тапшырылган азык - төлек товарлары өчен акча эшкәртүдән яки сатудан соң 5 көннән дә соңга калмыйча товар иясенең исәп - хисап счетына яки ул күрсәткән адрес буенча күчерелә.

Гражданнарның сәламәтлегенә һәм тормышына куркыныч тудырулары сәбәпле сатарга яки промышленностьта эшкәртергә ярамаган азык - төлек товарлары юкка чыгарылырга тиеш.

Кулланырга яраксыз, шулай ук гражданнарның сәламәтлеге һәм тормышы өчен зарарлы булулары сәбәпле юкка чыгарылырга тиешле азык - төлек товарларының бәясе ияләренә кире кайтарылмый. Киресенчә, андый товарларның ияләренә ул продукцияне юкка чыгару чыгымнарын каплау бурычы да йөкләнергә мөмкин.

Продукция махсус комиссия тарафыннан юкка чыгарыла. Аның составы шәһәр, район хакимияте тарафыннан раслана. Продукциянең юкка чыгарылуы турында аның кемнеке булуын, исемен һәм микъдарын күрсәтеп акт төзелә. Актка комиссиянең барлык членнары да кул куя.

Тоткарланган продукцияне юкка чыгару Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасының әйләнә - тирә табигый мохитне саклау турындагы таләпләрен үтәп башкарыла.

# Котлыйбыз!



Урта Чаллы авылында яшәүче **Мәксутҗан Хафиз улы һәм Сания Гарифулла кызы Вафиннарның** бергә гомер итүләренә 40 ел. Әти - әни! Сәламәт яшәгез, килер көннәрегез тигез, имин, якты булсын, һәркем өчен кирәклегегезне, балаларыгыз, оныкларыгыз өчен кадерле булуыгызны тоеп тату гомер итегез.

**Балаларыгыз, кияүләрегез, киленегез, оныкларыгыз.**



Урта Чаллы авылында яшәүче **кадерле әниебез, әбиебез Миннегөл Вәлиеваны** туган көне белән котлыйбыз. Аңа исәнлек, озын гомер, тыныч картлык телибез, балаларының игелеген тоеп яшәргә язсын.

**Нурлат шәһәрендә яшәүче балалары һәм оныклары**

# БЕЛДЕРҮЛӘР. РЕКЛАМА

## САТАБЫЗ

**"Москвич - 412", 5 мең сум.**
Салдакайда Евдокимовларга мөрәҗәгать итәргә.

***

**Кормыш ягында бер бүлмәле фатир.**
Арадашчы тел.: 5-17-47.

***

**1991 елгы ВАЗ - 2107.** Тел.: 2-12-75.

***

**НГДУ ЖКХсы каршында капиталь гараж.** Тел.: 2-29-11.

***

**Туй күлмәге.** Тел.: 5-26-87.

***

**"Нефтяник" клубы янында ике бүлмәле фатир.** Циолковский ур., 31 - 1 адресы буенча мөрәҗәгать итәргә.

***

**Иң киме 35 сумнан Яңа ел бүләкләре.** Тел.: 5-39-39.

***

**Төргәктә яңа кул тегү машинасы.** Тел.: 5-22-73.

## АЛМАШТЫРАБЫЗ

**Зеленодольскидагы бер бүлмәле фатирны - Нурлатныкына.** Тел.: 2-29-24.

## ТӨРЛЕСЕННӘН

**Ике бүлмәле фатир сатып алам.** Тел.: 5-15-16.

***

**Ике бүлмәле фатирны өстәмә түләп бер бүлмәле фатирга алмаштырабыз. Капиталь ремонтланган ВАЗ - 2101 һәм иске чистарту корылмалары ягында гараж сатабыз.** Тел.: 5-36-74.

***

***"Надежда" дәүләт предприятиесе фотохезмәтләр тәкъдим итә:***

**20 минут эчендә документларга фото ясау, түбән бәягә "Кодак" төсле фотоларын ачыгайту, ясау.**

Адрес: Мәктәп ур., Көнкүреш йорты, 1нче кат.




***Җанварлар циркы балаларны Дуров бабайның могҗизалар дөньясына чакыра.***



***Программада - өйрәтелгән аюлар, крокодиллар, вараннар һәм башка хайваннар. Сезне шулай ук шаян шамакайлар һәм фокусчы - иллюзионист белән очрашу көтә.***

***Цирк район мәдәният йортында 3 нче декабрь көнне 10.00 һәм 14.00 сәгатьләрдә була.***

***Билет бәясе 10 сум.***

***Идел Буе региональ наркология үзәге***

*Алкогольгә бәйлелектән һәм тәмәке тартудан бер сеанста кодлаштыру.*

***Табиб М.Б.Багрянцев.***

**Бездә генә!**

**Тулы анонимлык. Индивидуаль якын килү. Дәвалау барышында пациентның туганнарына да катнашырга рөхсәт ителә. Белешмә бирелә. Консультация, әңгәмә, кодлаштырудан соң күзәтү һәм ярдәм - бушлай!**

**Язылу һәм әңгәмә дәвалау көнне, җомга - 11нче һәм 27 нче декабрьдә көндезге сәгать 12дә район мәдәният йорты бинасында уздырыла.**

РФ Сәламәтлек саклау министрлыгыннан 1995 елның 16 гыйнварында бирелгән № 00164 - 30 лицензия.


# Җанга якын таныш җыр...



Күптән түгел безгә Ульян шәһәрендә Чуваш җыры фестивалендә катнашу бәхете тәтеде. Чуваш теле һәм әдәбияты укытучысы Геннадий Михайлович һәм музыка укытучыбыз Сергей Михайлович Ендиряковларның башына килде ул уй. Репертуарыбызга җырларның төрлесен - үтеп баручы балачак, укытучылар, мәхәббәт турындагыларын да алдык.

... "Тавыш бир, чуваш улы" дигән II фестиваль сәгать 11дә башланды. Безне, Татарстан вәкилләрен колач җәеп каршыладылар, әзерләнер өчен үзебезгә бер бүлмә бирделәр. Без, авыл балалары башта бик нык каушап та калдык - зур шәһәрдә өлкә сәхнәсенә беренче генә чыгуыбыз бит. Әмма дулкынлануларыбыз бик тиз басылды һәм без уңышлы чыгыш ясадык. Безгә милли сәнгатебезгә сак мөнәсәбәт өчен диплом тапшырдылар.

Шундый зур бәйгедә катнашуыбызны оештырган өчен укытучыларыбызга чиксез рәхмәтле без.

**А.АКМУЛЛИНА, И.ПАЙДУГАНОВА, О.СЕНДЮКОВА.**

**Аксумла урта мәктәбе.**



Н.АЗИЗОВ фотосы.

# «Ровесник» яшь, эшли

***Шушы көннәрдә "Ровесник" үсмерләр клубы үзенең 10 еллыгын билгеләп үтте.***

Моннан 10 ел элек, база хуҗалыгы - "Нурлатнефть" НГДУсы, байтак промышленность предприятиеләре ярдәме белән ачылган һәм элек социаль - педагогик комплекс составында ипле генә яшәп килгән үсмерләр клубын да замана җиле читләп үтмәде. Әмма ни гаҗәп: "Ровесник" "Татнефть" берләшмәсендәге башка клублар белән чагыштырганда җилләргә чыдамрак булды, берүзе генә калса да яшәвен дәвам итә. Бүген дә ул шәһәрдәге иң катлаулы саналган Кормыш микрорайоны үсмерләренең яратып йөри торган урыны санала. Бирергә тегү, драма, радиотехника түгәрәкләре уңышлы эшләп киләләр. Мөгаен, клубның бүгенгәчә яшәвендә "Нурлатнефть" НГДУсының алар мәнфәгатенә җылы карашы да зур роль уйнагандыр. Әмма тагын бер алшарт шунда: 10 ел буе аның җитәкчесе булып инициативалы һәм тырыш директор С.Ф. Захарова эшли, клуб учагын сүндермәү өчен бар тырышлыгын куя. Клубның ун еллык юбилее тантанасында да бу хакта да сүз булды. Бу көнне кунаклар - "Нурлатнефть" НГДУсы профкомы, 4нче мәктәп вәкилләре чын иҗади бәйрәм шаһиты булдылар. Һәр түгәрәк үзенчәлекле котлавын тәкъдим итте, иҗади уңышларын тәкъдирләде: модалар күрсәтелде, артистлар чыгыш ясады. Кунаклар котлавына кайчандыр бирегә яратып йөргән, хәзер үзләре ата - ана булгач та клуб турында иң якты хатирәләр саклаган өлкәннәр дә кушылдылар, һәммәсе "Ровесник"ка озын, нәтиҗәле гомер теләделәр.

**Р.ГИНЯЕВА,**

**4нче мәктәп директоры.**

МӨХӘРРИР **С.Н.ХӘЙРУЛЛИНА**


**Учредительләр: Нурлат район хакимияте һәм редакциянең хезмәт коллективы.**

**"Дуслык" район газетасы атнаның чәршәмбе, җомга, шимбә көннәрендә чыга, рус һәм чуваш телләренә тәрҗемә ителә.**

**Безнең адрес: 423000, Татарстан Республикасы, Нурлат шәһәре, Карл Маркс урамы, 19. Телефоннар: баш мөхәррир - 2-12-14, 2-22-81, мөхәррир һәм җаваплы сәркәтип - 2-18-67, авыл хуҗалыгы бүлеге - 2-22-51, Советлар, хатлар һәм җәмәгать оешмалары тормышы, чуваш теленә тәрҗемә буенча мөхәррир - 2-10-44, рус теленә тәрҗемә буенча мөхәррир - 2-14-16, бухгалтерия, реклама бүлеге, фотокорреспондент - 2-15-63.**

***Газета Татарстан Республикасының мәгълүмат һәм матбугат Министрлыгында 34 нче номерлы таныклык белән теркәлде.***

Ульяновск өлкәсе матбугат һәм мәгълүмат идарәсенең Димитровград типографиясе. Офсет ысулы белән басылды. Күләме - 1 басма табак. Тираж 2361 данә. 4648